| | | |
|---|---|---|
| ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ<br>ЗЕЛЕНОДОЛЬСКОГО<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА<br>РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>ЗЕЛЕНОДОЛЬСК<br>МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ<br>БАШКАРМА КОМИТЕТЫ |
| **ПОСТАНОВЛЕНИЕ**<br>**10.04.2020** | Зеленодольск<br>шәһәре | **КАРАР**<br>**№ 641** |

Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы бюджетыннан, җәмәгать транспорты хезмәтләреннән аерым категориядәге гражданнарны исемле электрон бердәм социаль юлда йөрү билеты буенча ташудан бертигез дәрәҗәдә файдалану мөмкинлеген тәэмин итүгә бәйле алынмаган керемнәрне каплау максатларында, оешмаларга субсидияләр бирү тәртибе турындагы нигезләмәне раслау хакында

Россия Федерациясе Бюджет кодексының 78 статьясы, «Юридик затларга (дәүләт (муниципаль) учреждениеләргә субсидияләрдән тыш), индивидуаль эшмәкәрләргә, шулай ук товарлар, эшләр һәм хезмәт күрсәтүләр җитештерүчеләргә физик затларга субсидия бирүне җайга салучы норматив хокукый актларга, муниципаль хокукый актларга гомуми таләпләр турында» Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2016 елның 6 сентябрендәге 887 номерлы карары, «Татарстан Республикасында муниципаль берәмлекләрнең җирле үзидарә органнарына Татарстан Республикасы территориясендә гражданнарның аерым категорияләре өчен җәмәгать транспорты хезмәтләреннән бертигез дәрәҗәдә файдалану мөмкинлеген тәэмин итү өлкәсендә аерым дәүләт вәкаләтләрен бирү турында» 2008 елның 19 декабрендәге 123-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында айлык бердәм социаль юл билетын һәм айлык бердәм балалар социаль юл билетын бирү тәртибен раслау турында» 2005 елның 07 апрелендәге 161 номерлы карары нигезендә, Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты

**КАРАР БИРӘ:**

1. Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы бюджетыннан, җәмәгать транспорты хезмәтләреннән аерым категориядәге гражданнарны исемле электрон бердәм социаль юлда йөрү билеты буенча ташудан бертигез дәрәҗәдә файдалану мөмкинлеген тәэмин итүгә бәйле алынмаган керемнәрне каплау максатларында, оешмаларга субсидияләр бирү тәртибе турындагы нигезләмәне әлеге карарга кушымта рәвешендә расларга.

2. Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы Советы аппаратының җәмәгатьчелек һәм массакүләм мәгълүмат чаралары белән элемтә бүлегенә әлеге карарны интернет челтәрендәге Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында .http://pravo.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталы составында Зеленодольск муниципаль районының мәгълүмати сайтында (http://zelenodolsk.tatarstan.ru ) бастырып чыгарырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Җитәкче М. П. Афанасьев

Татарстан Республикасы
Зеленодольск муниципаль районы
Башкарма комитетының
2020 елның 10 апрелендәге 641
номерлы карарына
кушымта

**Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы бюджетыннан, җәмәгать транспорты хезмәтләреннән аерым категориядәге гражданнарны исемле электрон бердәм социаль юлда йөрү билеты буенча ташудан бертигез дәрәҗәдә файдалану мөмкинлеген тәэмин итүгә бәйле алынмаган керемнәрне каплау максатларында, оешмаларга субсидияләр бирү тәртибе турында нигезләмә**

## 1. Гомуми нигезләмәләр

1.1. Россия Федерациясе Бюджет кодексының 78 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы бюджетыннан, җәмәгать транспорты хезмәтләреннән аерым категориядәге гражданнарны исемле электрон бердәм социаль юлда йөрү билеты буенча ташудан бертигез дәрәҗәдә файдалану мөмкинлеген тәэмин итүгә бәйле алынмаган керемнәрне каплау максатларында, оешмаларга субсидияләр бирү тәртибе турында нигезләмә (алга таба - Нигезләмә) Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы бюджетыннан гражданнарның аерым категорияләре өчен җәмәгать транспорты хезмәтләреннән бертигез файдалануны тәэмин итүгә бәйле чыгымнарны каплау өчен субсидияләр күләмен һәм шартларын билгеләү процедурасын регламентлый (алга таба - субсидия).

1.2. Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы территориясе буенча йөрүче муниципаль һәм муниципальара маршрутларда гомуми файдаланудагы пассажирлар ташу эшчәнлеген гамәлгә ашыручы юридик затларга, индивидуаль эшкуарларга, җәмәгать транспорты хезмәтләреннән аерым категориядәге гражданнарны исемле электрон бердәм социаль юлда йөрү билеты буенча ташудан бертигез дәрәҗәдә файдалану мөмкинлеген тәэмин итүгә бәйле алынмаган керемнәрне каплау максатларында, субсидияләр бирелә.

1.3. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында бердәм айлык социаль йөртү билетын һәм балалар өчен бердәм айлык социаль йөртү билетын бирү тәртибен раслау турында» 2005 елның 7 апрелендәге 161 номерлы карары (алга таба - ТР МК 2005 елның 7 апрелендәге 161 номерлы карары) нигезендә кертелгән, гражданнарның аерым категорияләре өчен транспорт хезмәтләреннән бертигез файдалану мөмкинлеге, шул исәптән айлык бердәм социаль юл билетларын һәм айлык бердәм балалар социаль юл билетларын сату юлы белән тәэмин ителә.

1.4. Субсидия бирү түләүсез һәм кире кайтарылмый торган нигездә гамәлгә ашырыла һәм максатчан характерга ия.

1.5. Субсидия Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты күрсәтмәсе нигезендә бирелә.

1.6. Субсидия бирүгә вәкаләтле орган булып Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты тора.

## 2. Субсидия бирү максатлары һәм субсидия алу хокукына ия затларны сайлап алу критерийлары

2.1. Субсидия түләүсез һәм кире кайтарылмый торган нигездә, җәмәгать транспорты хезмәтләреннән аерым категориядәге гражданнарны исемле электрон бердәм социаль юлда йөрү билеты буенча ташудан бертигез дәрәҗәдә файдалану мөмкинлеген тәэмин итүгә бәйле алынмаган керемнәрне каплау максатларында, бирелә.

2.2. Субсидияләр түбәндәге критерийларга туры килергә тиешле оешмаларга, шәхси эшмәкәрләргә бирелә:

- субсидия алучыларның, салымнар һәм җыемнар турында Россия Федерациясе законнары нигезендә түләнергә тиеш салымнар, җыемнар, иминият кертемнәре, пенялар, штрафлар, процентлар түләү буенча үтәлмәгән йөкләмәләр булмау;

- субсидия алучыларның Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы бюджетына субсидияләрне, бюджет инвестицияләрен, шул исәптән башка хокукый актлар нигезендә бирелгән, кире кайтару буенча вакыты чыккан бурыч һәм Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы бюджеты каршында бүтән вакыты чыккан бурыч булмау;

- субсидия алучылар - юридик затлар үзгәртеп кору, бетерү процессында булырга тиеш түгел, аларга карата банкротлык процедурасы кертелмәгән, субсидия алучыларның эшчәнлеге Россия Федерациясе законнарында каралган тәртиптә туктатылмаган, ә субсидия алучылар - шәхси эшмәкәрләр эшчәнлеген, шәхси эшмәкәрләр буларак, туктатырга тиеш түгел;

-Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы территориясе буенча йөрүче муниципаль һәм муниципальара маршрутларда гомуми файдаланудагы транспорт белән пассажирлар йөртүне оешма, шәхси эшмәкәр гамәлгә ашыра;

- субсидия алучылар чит ил юридик затлары, шулай ук устав (тупланма) капиталларында теркәү урыны Россия Федерациясе Финанс министрлыгы раслаган салым салуның ташламалы салым режимын бирә һәм (яки) финанс операцияләре үткәргәндә мәгълүмат ачуны һәм бирүне күздә тотмый торган дәүләтләр һәм территорияләр (офшор зоналар) исемлегенә кертелгән дәүләттә яки территориядә булган чит ил юридик затлары өлеше мондый юридик затларга мөнәсәбәттә гомумән алганда 50 проценттан арткан россия юридик затлары , шулай ук чит ил юридик заты булмаска тиеш түгел;

- субсидияләр алучылар, әлеге нигезләмәдә күрсәтелгән максатларга башка норматив хокукый актлар яисә муниципаль хокукый актлар нигезендә, Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы бюджетыннан акча алырга тиеш түгел.

2.3. Субсидияләр алучылар әлеге Нигезләмәнең 2.2 пунктында күрсәтелгән таләпләргә, субсидия бирелә торган елның 01 гыйнварына, туры килергә тиеш.

2.4. Субсидия бирү нәтиҗәләре булып, җәмәгать транспорты хезмәтләреннән аерым категориядәге гражданнарны исемле электрон бердәм социаль юлда йөрү билеты буенча ташудан бертигез дәрәҗәдә файдалану мөмкинлеген тәэмин итүгә бәйле, алынмаган керемнәрне компенсацияләү тора.

## 3. Субсидия бирү шартлары

3.1. Субсидияләр бирү шарты булып, җәмәгать транспорты хезмәтләреннән аерым категориядәге гражданнарны исемле электрон бердәм социаль юлда йөрү билеты буенча ташудан бертигез дәрәҗәдә файдалану мөмкинлеген тәэмин итүгә бәйле , алынмаган керемнәр булуы тора.

3.2. Субсидия күләме түбәндәге формула буенча исәпләнә:

$$\mathbf{K_{комп.} = ((SUM\ (T_{гор} x П_{гор}) + SUM\ (T_{пр}\ x\ P_{пр})) – B_{тр.орг}}$$

биредә:

$\mathbf{T_{гор}}$- Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районында законнар нигезендә билгеләнгән, шәһәр элемтәсендәге пассажирлар йөртүнең гамәлдәге тарифы;

Ташламалы транспорт кушымтасы булган электрон карта белән йөргәндә, 50 һәм аннан да күбрәк тапкыр йөрү өчен тарифлар кулланыла, ул Татарстан Республикасы Дәүләт комитетының тарифлар буенча карары белән билгеләнгән;

$\mathbf{T_{пр}}$ -Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районында закон нигезендә шәһәр яны (муниципальара) элемтәсендәге маршрутта пассажирлар йөртүнең гамәлдәге тарифы;

$\mathbf{P_{пр}}$-хисап аенда шәһәр яны элемтәсендә йөрү өчен автоматлаштырылган түләү системасы (АСОП) мәгълүматлары буенча башкарылган пассажирлар-километрлар саны;

$\mathbf{П_{гор}}$-транспорт оешмасы буенча хисап аена юл йөрү билетлары һәм балалар йөрү билетлары буенча йөрүләрнең үтелгән саны:

шәһәр яны элемтәсенең шәхсиләштерелгән исәпкә алынуы булганда - шәһәр элемтәсендәге транзакцияләрнең факттагы саны;

$\mathbf{B_{тр.орг}}$ - -транспорт оешмасының бердәм айлык социаль юл йөрү билетын (ЕМСПБ) һәм балалар өчен бердәм айлык социаль юл йөрү билетын (ЕМДСПБ) сатудан (тулыландырудан) кереме.

## 4. Субсидия бирү тәртибе

4.1. Әлеге нигезләмә нигезендә алынмаган керемнәрне каплауга субсидия алу өчен Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы бюджетында каралган чаралар чикләрендә субсидияләр алуга дәгъва кылучылар, йә гаризаны һәм субсидия алуга документларны (алга таба - мөрәҗәгать итүчеләр) алуга вәкаләтле башка затлар Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетына түбәндәге документларны тапшыралар:

1. субсидия алу өчен гариза;

2. уставның күчермәсен (юридик затлар өчен);

3. дәүләт теркәве турында таныклык күчермәсе (юридик затлар, шәхси эшмәкәр өчен);

4. салым органында исәпкә кую турында таныклык күчермәсе;

5. хисап балансының күчермәсе соңгы хисап датасына (1 нче форма);

6. соңгы хисап датасына (юридик затлар өчен) керемнәр һәм чыгымнар турында хисап күчермәсе (2 нче форма);

7. керемнәр һәм чыгымнарны һәм хуҗалык операцияләрен исәпкә алу кенәгәсеннән өземтә (салым салуның гадиләштерелгән системасын кулланучы шәхси эшмәкәр һәм юридик затлар өчен);

8. җәмәгать транспорты хезмәтләреннән аерым категориядәге гражданнарны исемле электрон бердәм социаль юлда йөрү билеты буенча ташудан бертигез дәрәҗәдә файдалану мөмкинлеген тәэмин итү буенча транспорт оешмалары тарафыннан тотылган чыгымнар турында хисап.

9. исемле электрон бердәм социаль юлда йөрү билеты буенча пассажирлар йөртүне гамәлгә ашыруга бәйле рәвештә компенсацион түләүләрне исәпләү;

10. хисап сәясәтен раслау турында боерык күчермәсе;

11. исәпкә алу сәясәтенең күчермәсен;

12. штат расписаниесе күчермәсе;

13. субсидия бирү өчен гариза язган һәм/яки документлар биргән ,оешма җитәкчесе вәкаләтләрен һәм оешма вәкаләтләрен раслаучы, документ күчермәсе;

14.лицензияләнгән эшчәнлек төрләрен Россия Федерациясе законнары һәм аның оригиналы нигезендә лицензияләнгән эшчәнлек алып барган очракта, хуҗалык эшчәнлеген гамәлгә ашыруга лицензия күчермәсен (оригиналы - күзәтүләр өчен);

15. «Зеленодольск муниципаль районының финанс-бюджет палатасы» МУ тарафыннан бирелгән бюджет кредиты шартнамәләре булу (булмау)турында белешмә;

16. юридик затларның бердәм дәүләт реестрыннан (юридик затлар өчен) өземтә, шәхси эшмәкәрнең бердәм дәүләт реестрыннан өземтә (шәхси эшмәкәрләр өчен);

17. бюджет системасының барлык дәрәҗәләрдәге бюджетлар алдындагы срогы чыккан бурыч булмауны раслый торган документның күчермәсен;

18. Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы территориясе аша узучы муниципаль һәм муниципальара маршрутларда гомуми файдаланудагы транспортта пассажирлар йөртү эшчәнлеген гамәлгә ашыру өчен кирәкле транспорт чараларының милек хокукында яисә башка законлы нигездә булуын раслый торган документлар күчермәләре;

19. бирелгән документларда белешмәләрнең дөреслеген тикшерү турында мөрәҗәгать итүчеләрнең ризалыгы.

Гаризага мөрәҗәгать итүченең (шәхси эшмәкәр, юридик зат вәкиле) имзасы һәм мөһере(булган очракта) белән таныкланган төп нөсхәләре яисә документларның күчермәләре кушымта итеп бирелә.

Мөрәҗәгать итүче гаризага башка документларны да, йә аларның тиешенчә расланган күчермәләрен беркетергә хокуклы.

Әгәр мөрәҗәгать итүче, агымдагы елның 01 гыйнварыннан 31 декабренә кадәр Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетына әлеге нигезләмә нигезендә субсидияләр бирү турында әлеге пунктта күрсәтелгән документларны кушып гариза юллаган булса, элек тапшырылган документлары үзгәргән очракта, документларны кабат бирергә кирәк була.

4.2. Субсидияләр бирү турындагы гаризаларны һәм аларга кушып бирелә торган документларны карауны Комиссия (алга таба - комиссия) башкара.

Комиссиянең персональ составы Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе боерыгы белән раслана. Комиссия әгъзалары саны-5.

Комиссия тапшырылган документларны карый һәм тапшырылган документларның әлеге нигезләмә таләпләренә туры килү-килмәве турындагы бәяләмәне , әлеге документлар кергәннән соң, 5 (биш) эш көне дәвамында әзерли.

Комиссия утырышы, әгәр анда 3 (өч) һәм аннан күбрәк әгъзасы катнашса, хокуклы дип санала. Комиссия әгъзалары комиссия утырышларында алыштыру хокукыннан башка катнаша. Комиссия әгъзасы, утырышта булмаса, карала торган мәсьәләләр буенча, үз фикерен язма рәвештә бәян итәргә хокуклы.

Комиссия карары комиссия әгъзаларының гомуми саныннан күпчелек тавыш белән кабул ителә.

Комиссия карарлары, комиссия утырышында катнашкан йә үз фикерен язма рәвештә юллаган, комиссия рәисе һәм әгъзалары имзалый торган бәяләмә белән рәсмиләштерелә.

Бирелгән документларның таләпләргә туры килүе турында комиссия бәяләмәсе нигезендә, әлеге нигезләмәнең 5 (биш) эш көне эчендә, Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетының субсидия бирү турындагы боерыгы чыгарыла.

Комиссия бәяләмәсе нигезендә бирелгән документларның әлеге нигезләмә таләпләренә туры килмәве турында 5 (биш) эш көне эчендә субсидия бирүдән баш тарту турында Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты боерыгы чыгарыла.

Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты боерыгы гариза бирүчегә субсидия бирү яисә субсидия бирүдән баш тарту турында мөрәҗәгать итүчегә аның басылып чыккан көненнән 3 (өч) эш көне эчендә җибәрелә. Субсидия бирүдән баш тарту турындагы карар мотивлаштырылган булырга тиеш.

4.3. Субсидия бирүдән баш тарту өчен түбәндәгеләр нигез булып тора:

- мөрәҗәгать итүченең әлеге Нигезләмәнең 1.2 пунктында билгеләнгән субсидияне алучылар категорияләренә һәм (яисә) әлеге Нигезләмәнең 2.1, 2.2 пунктларында күрсәтелгән максатларга һәм критерийларга туры килмәве;
- мөрәҗәгать итүчеләр тарафыннан әлеге Нигезләмәнең 4.1 пунктында каралган документларны тапшырмавы;
- әлеге Нигезләмәнең 4.1 пунктында каралган документлар тулы күләмдә тапшырылмавы;
- 4.1 пункты нигезендә каралган документлар. Нигезләмәләр гамәлдәге

закон таләпләренә туры килмәве;

- субсидия алучы тарафыннан бирелгән мәгълүматның дөрес булмавы;

- әлеге нигезләмәнең 2.1 пунктында күрсәтелгән максатларга каралган лимитларның Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы бюджетында булмавы.

4.4. Субсидияләр бирү чираттагы финанс елына җирле бюджетта каралган ассигнованиеләр һәм бюджет йөкләмәләре лимитлары чикләрендә гамәлгә ашырыла.

4.5. Субсидияләр, әлеге нигезләмәнең 2.1 пунктында күрсәтелгән максатларга акчалар булганда, субсидия бирү турында килешү имзаланган көнгә кадәр барлыкка килгән , алынмаган керемнәргә карата субсидия бирү турында килешү төзелгән көннән алып 5 (биш) эш көне эчендә, алучыга күчерелә. Алга таба субсидияләр алучыга, әлеге нигезләмәнең 2.1 пунктында күрсәтелгән максатларга Зеленодольск муниципаль районы бюджетында акчалар булганда, Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетына әлеге нигезләмәнең 4.1 пунктындагы «7», «8», «9» пунктчаларында каралган документлар бирелгән көннән алып, ай саен 5 (биш) эш көне эчендә , күчерелә. Әлеге нигезләмәнең 2.1 пунктында күрсәтелгән максатларга акча булмаган очракта, субсидия, Зеленодольск муниципаль районы бюджетына акча кергән көннән алып, 3 (өч) эш көне эчендә күчерелә.

РФ БК 78 статьясындагы 5.1 өлеше нигезендә, субсидия алучыларга, Россия Федерациясенең валюта законнары нигезендә, югары технологияле чит ил җиһазлары, чимал һәм комплектлаштыру эшләнмәләре сатып алганда гамәлгә ашырыла торган операцияләрдән, субсидия бирүне җайга сала торган норматив хокукый актлар, муниципаль хокукый актлар белән билгеләнгән һәм әлеге акчаларны бирү максатларына ирешү белән бәйле башка операцияләрдән тыш, алынган акчалар хисабына чит ил валютасы сатып алу тыела.

4.6. Субсидия бирү өчен нигез булып, субсидия алучылар һәм Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты арасында Россия Федерациясе законнары һәм әлеге Нигезләмә нигезендә төзелгән , Субсидия бирү турында килешү (әлеге Нигезләмәнең кушымтасына туры китереп) тора.

4.7. Субсидия бирү турындагы килешүдә түбәндәгеләр каралырга тиеш:

- субсидия алучыга бирелә торган субсидия күләме турында белешмәләр;

-субсидия күчерүнең максатлары, шартлары, тәртибе һәм сроклары (периодик) ;

- субсидияне биргәндә билгеләнгән шартлар бозылган очракта,Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы бюджетына аны кире кайтару тәртибе,

- агымдагы финанс елында субсидия алучы тарафыннан субсидияләр бирү турындагы килешүдә каралган очракларда, хисап финанс елында файдаланылмаган субсидия калдыкларын кире кайтару тәртибе.

4.8. Субсидия алучылар әлеге Нигезләмәнең 4.1 пунктында күрсәтелгән документларда бирелгән мәгълүматның дөреслеге өчен, гамәлдәге законнарда каралган, җаваплылык тоталар.

4.9. Субсидияләр Россия Федерациясе территориясендә урнашкан, кредит оешмасында ачылган, субсидия алучыларның исәп-хисап счетларына

башкарыла.

4.10. Субсидия алучылар һәр айның 1 числосына, хисаптан соң килгән айның 6 числосыннан да соңга калмыйча, Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетына комитетына финанс белән тәэмин итү чыганагы субсидия булган чыгымнар турында хисап тапшырырга тиеш.

Хисаплар, агымдагы финанс елының декабрь ае өчен субсидияләр алучылар тарафыннан, агымдагы финанс елының беренче 10 эш көне дәвамында бирелә.

4.11. Субсидия бирү турындагы килешү Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетының вәкаләтле вазыйфаи заты тарафыннан имзалана һәм субсидия алучыга (яисә аның вәкаләтле затына) субсидия бирү турында боерык чыккан көннән соң өч эш көне эчендә заказлы хат белән җибәрелә. Субсидия алучы Килешүнең нөсхәләренә кул куярга һәм аларны Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетына (Субсидия алучыда калган бер нөсхәдән тыш), Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты тарафыннан килешү нөсхәләрен алганнан соң, өч эш көне эчендә тапшырырга тиеш.

4.12. Субсидия чыганагы булып Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы бюджеты тора.

## 5. Субсидияләрне кире кайтару тәртибе

5.1. Субсидия алучы тарафыннан , субсидия биргәндә билгеләнгән шартлар бозылган очракта, Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты, күрсәтелгән хокук бозулар ачыкланганнан соң, 10 көн эчендә субсидия алучыга субсидияне кире кайтару турында хәбәр җибәрә.

5.2. Әлеге Нигезләмәнең 5.1 пунктында күрсәтелгән шартлар ачыкланганда, субсидияләр алучылар субсидияне мөстәкыйль рәвештә яисә Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты таләбе буенча бюджетка кайтаралар.

5.3. Акчаны кире кайтару, субсидия алучыга субсидияне кире кайтару турындагы таләпне җиткергәннән соң, җиде эш көне эчендә, әмма агымдагы елның 31 декабреннән дә соңга калмыйча, гамәлгә ашырыла.

5.4. Субсидияләрне кире кайтару, хәбәрнамәдә күрсәтелгән, Россия Федерациясе бюджетлары керемнәрен классификацияләү реквизитлары һәм кодлары буенча башкарыла.

5.5. Субсидия алучылар бирелгән документларны тикшерү нәтиҗәләре буенча билгеләнгән, шулай ук башка контроль чаралар уздыру нәтиҗәсендә, фактта барлыкка килгән керемнәрне нигезсез рәвештә күрсәтү күләмендә бирелгән керемнәр суммасының нигезләнмәве ачыкланган очракта, субсидияләр рәвешендә алынган бюджет акчаларын кире кайтарырга тиеш.

Ачыкланган бозулар акт белән рәсмиләштерелә, ул комиссия тарафыннан имзалана һәм Йөртүчегә -субсидия алучыга бирелә.

5.6. Әлеге нигезләмәнең 5.5 пунктында күрсәтелгән актны алган көннән , 30 календарь көннән дә артык булмаган вакыт эчендә, субсидия алучы

Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетының шәхси счетына агымдагы финанс елында алынган акчаларны кире кайтарырга тиеш.

5.7. Әлеге Нигезләмәнең 5.3., 5.6 п. үтәлмәгән сумма недоимка булып санала һәм аңа билгеләнгән һәр көн өчен 0,1% күләмендә пени өстәлә.

5.8. Субсидияләр биргәндә билгеләнгән шартларны бозып файдаланылган субсидияне, шулай ук тикшерү нәтиҗәләре буенча ачыкланган төшеп калган керемнәрнең нигезсез суммаларын, субсидияне ирекле рәвештә кире кайтарудан баш тарткан очракта яисә кире кайтармаган очракта, түләтү Россия Федерациясе законнары нигезендә суд тәртибендә башкарыла.

## 6. Субсидияләр калдыкларын кире кайтару тәртибе

6.1. Субсидия алучы агымдагы финанс елында субсидия алучының хисап елында субсидиянең әлеге калдыкларын, субсидия бирү турындагы килешүдә каралган очракта, финанс ягыннан тәэмин итү чыганагы булып торган субсидия алучының акчалата йөкләмәләрен түләү өчен кирәкле сумма чикләрендә бирелгән субсидияләрдән тыш, субсидия алучы киләсе финанс елында субсидияләрнең калган калдыкларын кире кайтаруны гамәлгә ашыра.

6.2. Субсидиянең калган өлешләрен кире кайтару, субсидияне кире кайтару турындагы таләпне субсидия алучыга җиткергән көннән алып, Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетына тиешле чараларны күчерү юлы белән, агымдагы финанс елның 31 декабреннән дә соңга калмыйча, җиде банк көне дәвамында гамәлгә ашырыла.

6.3. Агымдагы елның декабренә бирелгән субсидия бу айда алучыга туры килә торган субсидиядән артып китсә, артык сумма, агымдагы елның 25 гыйнварына кадәр, Зеленодольск муниципаль районы бюджетына кире кайтарылырга тиеш.

## 7. Субсидияләр бирү шартларын,максатларын һәм тәртибен үтәүне контрольдә тоту

7.1. Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты һәм муниципаль финанс контроле органы («ЗМР контроль-хисап палатасы» МУ) билгеләнгән тәртиптә субсидияләр бирү шартларының, максатларының һәм тәртибенең үтәлеше буенча мәҗбүри тикшерүне гамәлгә ашыралар.

7.2. Әлеге Нигезләмәнең 7.1 пунктында күрсәтелгән контрольне гамәлгә ашырганда, анда күрсәтелгән органнар субсидия алучыдан һәм комиссия әгъзаларыннан, әлеге контрольне гамәлгә ашыру өчен , кирәкле һәм җитәрлек мәгълүматны соратып алырга хокуклы.

7.3. Субсидияләр биргәндә, аларны бирүнең мәҗбүри шарты булып, субсидия алучыларның Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты һәм муниципаль финанс контроле органы тарафыннан ("ЗМР контроль-хисап палатасы" МУ) субсидияләр бирү шартларының, максатларының һәм тәртибенең үтәлешен тикшерүгә ризалыгы тора. Күрсәтелгән ризалык, килешү турында әлеге шартны үз эченә алган,

субсидия бирү турында килешүне имзалау белән белдерелә.

## 8. Субсидияне кулланылуны тикшерү

8.1. Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетысубсидия бирү турында төзелгән килешү шартларының тиешенчә үтәлешен һәм хисаплылыкны үз вакытында тапшыруын контрольдә тота, субсидия бирүне туктату һәм (яки) субсидияләрне кире кайтару турында карар кабул итә.

Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы бюджетыннан, җәмәгать транспорты хезмәтләреннән аерым категориядәге гражданнарны исемле электрон бердәм социаль юлда йөрү билеты буенча ташудан бертигез дәрәҗәдә файдалану мөмкинлеген тәэмин итүгә бәйле алынмаган керемнәрне каплау максатларында, оешмаларга субсидияләр бирү тәртибе турында нигезләмәгә кушымта

**Субсидия бирү турында ____нче номерлы килешү**

«_____»____________20___ ел

Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты, алга таба «Башкарма комитет» дип аталучы зат __________________, гамәлдә булган ____________________________, бер яктан__________________, алга таба субсидия алучы дип аталучы затта ________________________, гамәлдә булган ____________________________, икенче яктан, түбәндәгеләр турында әлеге килешү төзеделәр.

## Килешү предметы

1.1. Килешү предметы булып, Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы территориясе аша уза торган муниципаль һәм муниципальара маршрутларда гомуми файдаланудагы транспортта пассажирлар ташу эшчәнлеген гамәлгә ашыручы субсидияләр алучыда барлыкка килгән зыянны каплау өчен түләүсез һәм кире кайтарылмый торган нигездә, җәмәгать транспорты хезмәтләреннән аерым категориядәге гражданнарны исемле электрон бердәм социаль юлда йөрү билеты буенча ташудан бертигез дәрәҗәдә файдалану мөмкинлеген тәэмин итүгә бәйле алынмаган керемнәрне каплауга, Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы бюджеты акчаларыннан субсидия алучыга субсидияләр бирү тора.

## 2. Якларның хокуклары һәм бурычлары

2.1. Башкарма комитет түбәндәгеләрне йөкләмә итеп ала:

2.1.1. Субсидия алучыга « Зеленодольск муниципаль районы бюджетыннан, җәмәгать транспорты хезмәтләреннән аерым категориядәге гражданнарны исемле электрон бердәм социаль юлда йөрү билеты буенча ташудан бертигез дәрәҗәдә файдалану мөмкинлеген тәэмин итүгә бәйле алынмаган керемнәрне каплау максатларында, оешмаларга субсидияләр бирү тәртибе турында нигезләмә» нигезендә гражданнарга транспорт хезмәтләре күрсәтүгә бәйле чыгымнарны капларга.

01.01.20__- 31.12.20__ еллары чоры эчендә.

2.2. Субсидия алучы түбәндәгеләрне йөкләмә итеп ала:

2.2.1. Ташламалы транспорт карталары буенча гражданнарга транспорт хезмәтләре күрсәтү.

2.2.2. Әлеге Килешүгә 2 нче кушымтада билгеләнгән форма буенча Башкарма комитетка хисап бирү өчен килә торган айның 6 числосыннан да соңга калмыйча, шулай ук исемле электрон социаль юлда йөрү билетлары буенча пассажирлар йөртүне һәм багаж ташуны гамәлгә ашыруга бәйле рәвештә компенсация түләүләрен әлеге Килешүгә 1 нче кушымтада билгеләнгән форма буенча исәпләү.

2.2.3. Агымдагы финанс елының декабрь ае өчен хисап субсидия алучы тарафыннан агымдагы финанс елының беренче 10 эш көне дәвамында бирелә.

2.3. Башкарма комитет субсидия алучы тарафыннан әлеге килешү буенча йөкләмәләрнең үтәлешен тикшерүне гамәлгә ашырырга, шулай ук субсидия алучыдан әлеге тикшерүне гамәлгә ашыру өчен кирәкле һәм җитәрлек мәгълүматны соратып алырга хокуклы.

2.4. Субсидия алучы Башкарма комитетка, Башкарма комитеттан тиешле сорату алынганнан соң 5 (биш) эш көне эчендә, өстәмә мәгълүмат бирүне үз өстенә ала.

### 3. Исәпләү шартлары һәм тәртибе

3.1. Субсидияләр, әлеге нигезләмәнең 2.1 пунктында күрсәтелгән максатларга акчалар булганда, субсидия бирү турында килешү имзаланган көнгә кадәр барлыкка килгән ,алынмаган керемнәргә карата субсидия бирү турында килешү төзелгән көннән алып 5 (биш) эш көне эчендә, алучыга күчерелә. Алга таба субсидияләр алучыга, әлеге нигезләмәнең 2.1 пунктында күрсәтелгән максатларга, Зеленодольск муниципаль районы бюджетында акчалар булганда, Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетына әлеге нигезләмәнең 4.1 пунктындагы «7», «8», «9» пунктчаларында каралган документлар бирелгән көннән алып, ай саен 5 (биш) эш көне эчендә , күчерелә. Әлеге нигезләмәнең 2.1 пунктында күрсәтелгән максатларга акча булмаган очракта, субсидия, Зеленодольск муниципаль районы бюджетына акча кергән көннән алып, 3 (өч) эш көне эчендә күчерелә.

3.2. Субсидия алучыга, югары технологияле чит ил җиһазларын, чималын һәм комплектлау әйберләрен сатып алганда Россия Федерациясенең валюта законнары нигезендә гамәлгә ашырыла торган, шулай ук әлеге акчаларны норматив хокукый актларда, күрсәтелгән юридик затларга субсидияләр бирүне җайга салучы муниципаль хокукый актларда билгеләнгән бүтән операцияләр максатларына ирешү белән бәйле операцияләрдән тыш, субсидиясе акчалары исәбеннән чит ил валютасы сатып алу тыела.

3.3. Башкарма комитет, әлеге килешү буенча йөкләмәләрне үтәмәү фактлары ачыкланган очракта, ачыкланган хокук бозуларны бетерүгә кадәр, Субсидия алучыга тиешле субсидияләрне күчермәскә хокуклы.

3.4. Субсидияләр, субсидия алучының Россия Федерациясендә урнашкан урыны булган кредит оешмасында, субсидия бирү турындагы гаризада күрсәтелгән исәп-хисап счетына күчерелә.

3.5. Субсидия алучы түбәндәгеләрне йөкләмә итеп ала:

3.5.1. Клиент - банк системасын кулланган очракта банк белән исәп-хисап счетыннан акча тотуның өстәмә контроленә мөнәсәбәтләрне рәсмиләштерергә, ә атап әйткәндә:

1) түләүләрне вакытлыча үткәрү режимы Мәскәү вакыты буенча 16:00 сәгатькә кадәр;

2) банкка Мәскәү вакыты белән 12: 00 сәгатькә кадәр, нарочно яки факс буенча, түләү документларын дистанцион банк хезмәте күрсәтү системасы аша җибәрелгән реестр бирү;

3) түләү документларының 1 000 000 сум һәм аннан да күбрәк суммасы булганда телефон яки электрон почта аша өстәмә килешү.

3.5.2. Клиент-банк системасын файдаланмаган очракта, банкка түләү документларын бары кәгазьдә генә тапшырырга тиеш.

## 4. Субсидияләрне кире кайтару тәртибе

4.1. Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты, субсидия алучы тарафыннан , субсидия биргәндә билгеләнгән шартлар бозылган очракта, күрсәтелгән хокук бозулар ачыкланганнан соң, 10 көн эчендә, субсидия алучыга субсидияне кире кайтару турында хәбәр җибәрә.

4.2. Әлеге Нигезләмәнең 4.1 пунктында күрсәтелгән шартлар ачыкланганда, субсидияләр алучылар субсидияне мөстәкыйль рәвештә яисә Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты таләбе буенча бюджетка кайтаралар.

4.3. Акчаны кире кайтару, субсидия алучыга субсидияне кире кайтару турындагы таләпне җиткергәннән соң, җиде эш көне эчендә, әмма агымдагы елның 31 декабреннән дә соңга калмыйча, гамәлгә ашырыла.

4.4. Субсидияләрне кире кайтару, хәбәрнамәдә күрсәтелгән, Россия Федерациясе бюджетлары керемнәрен классификацияләү реквизитлары һәм кодлары буенча башкарыла.

4.5. Субсидия алучылар бирелгән документларны тикшерү нәтиҗәләре буенча билгеләнгән, шулай ук башка контроль чаралар уздыру нәтиҗәсендә, фактта барлыкка килгән керемнәрне нигезсез рәвештә күрсәтү күләмендә бирелгән керемнәр суммасының нигезләнмәве ачыкланган очракта, субсидияләр рәвешендә алынган бюджет акчаларын кире кайтарырга тиеш.

Ачыкланган бозулар акт белән рәсмиләштерелә, ул комиссия тарафыннан имзалана һәм Йөртүчегә -субсидия алучыга бирелә.

4.6. Әлеге нигезләмәнең 4.5 п. күрсәтелгән актны алган көннән алып 30 календарь көн эчендә, субсидия алучы Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетының шәхси счетына агымдагы финанс елында алынган акчаларны кире кайтарырга тиеш.

4.7. Әлеге Нигезләмәнең 4.3., 4.6 п. үтәлмәгән сумма недоимка булып санала һәм аңа билгеләнгән һәр көн өчен 0,1% күләмендә пени өстәлә.

4.8. Субсидияләр биргәндә, билгеләнгән шартларны бозып файдаланылган, шулай ук төшеп калучы керемнәрнең нигезсез суммаларын тикшерү нәтиҗәләре буенча ачыкланган шартларны бозып кулланылган акчаларны, субсидияне ирекле кире кайтарудан яисә кире кайтарудан баш тарткан очракта, түләтү Россия Федерациясе законнары нигезендә, суд

тәртибендә башкарыла.

## 5. Субсидияләр калдыкларын кире кайтару тәртибе

5.1. Субсидия алучы, субсидия алучының акчалата йөкләмәләрен түләү өчен кирәкле сумма чикләрендә бирелгән субсидияләрдән тыш, агымдагы финанс елында субсидия калдыкларын кире кайтаруны гамәлгә ашыра.

5.2. Субсидия алучыга субсидияне кире кайтару турындагы таләпне җиткергән көннән алып, әмма агымдагы финанс елының 31 декабреннән дә соңга калмыйча, тиешле акчаларны Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетына күчерү юлы белән, калган субсидияләрне кире кайтару җиде банк көне эчендә гамәлгә ашырыла.

5.3. Агымдагы елның декабренә бирелгән субсидия бу айда алучыга туры килә торган субсидиядән артып китсә, артык сумма, агымдагы елның 25 гыйнварына кадәр, Зеленодольск муниципаль районы бюджетына кире кайтарылырга тиеш.

## 6. Йомгаклау нигезләмәләре

6.1. Әлеге килешүнең гамәлдә булу вакыты__________ _______________.

6.2. Әлеге килешү якларның үзара ризалыгы буенча үзгәртелергә яки тулыландырылырга мөмкин. Әлеге килешүгә теләсә нинди үзгәрешләр һәм өстәмәләр аларны язма рәвештә беркеткән һәм ике як та кул куйган очракта гына гамәлдә була.

6.3. Әлеге шартнамәгә кул кую белән субсидия алучы Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты һәм муниципаль финанс контроле органы («ЗМР Контроль-хисап палатасы» МУ) тарафыннан субсидияләр бирү шартларының, максатларының һәм тәртибенең үтәлешен тикшерүне гамәлгә ашыруга үзенең ризалыгын белдерә.

6.4. Әлеге килешү ике нөсхәдә төзелде: берсе субсидия алучыга һәм берсе Башкарма комитет өчен. Барлык нөсхәләр дә бертигез юридик көчкә ия.

## 7. Якларның адреслары һәм банк реквизитлары

| «Башкарма комитет» | «Субсидия алучы» |
|---|---|

## 8. Яклар имзалары

| «Башкарма комитет» | «Субсидия алучы» |
|---|---|
| _____________________ | _____________________ |
| М. У. | М. У |

Килешүгә 1 нче кушымта

«___»__________ № ______

Форма

**Пассажирлар йөртүне гамәлгә ашыру белән бәйле рәвештә компенсацион түләүләр бердәм электрон социаль юл йөрү билетлары буенча исәп-хисап**

___________ 20__ел
ай

| № т/б | Шәһәрдә социаль йөртү билетлары һәм балалар өчен социаль йөртү билетлары (транзакцияләрнең факттагы саны) буенча йөрелгән саны | АСОП мәгълүматларына караганда, шәһәр яны элемтәсендәге социаль йөртү билетлары һәм балалар өчен социаль йөртү билетлары буенча башкарылган пассажирокилометрлар саны | Ташламалы транспорт кушымтасы булган электрон карта белән түләгәндә шәһәр яны элемтәсендә пассажирлар йөртүгә гамәлдәге тариф - сум. | Шәһәр яны элемтәсендә пассажирлар ташуга гамәлдәге тариф, сум/км | Ташламалы транспорт карталары буенча транспорт хезмәтләре күрсәтүгә бәйле рәвештә транспорт оешмасы чыгымнары, сум. | Транспорт оешмасының ЕМСПБ һәм ЕМДСПБ сатудан (тулыландырудан) кереме, сум. | Ташламалы транспорт карталары буенча транспорт хезмәтләре күрсәтүгә бәйле рәвештә транспорт оешмаларына туры килә торган компенсация түләүләре күләме, сум. |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 |
| | | | | | | | |

Җитәкче _________________ ____________ ______________________
*(вәкаләтле зат, вазыйфасы (имза) (имза укылышы)*

Башкаручы ___________ ____________ ______________________
*(вазифасы) (ФИО) (телефон)*

«___» ____________ 20__ ел.

Килешүгә
2 нче кушымта
«___»__________ № ______
Форма

**Җәмәгать транспорты хезмәтләреннән аерым категориядәге гражданнарны исемле электрон бердәм социаль юлда йөрү билеты буенча ташудан бертигез файдалану мөмкинлеген тәэмин итү буенча транспорт оешмалары тарафыннан тотылган чыгымнар турында хисап**

**_____________________________ 20____ ел**

| № т/б | Транспорт оешмалары исеме | Файдаланылган ташламалы транспорт карталары/гамәлгә ашырылган ЕМСПБ һәм ЕМДСПБ хисап ае эчендә арта баручы нәтиҗә белән ,данә | | | Файдаланыла торган ташламалы транспорт карталары/гамәлгә ашырылган ЕМСПБ һәм ЕМДСПБдан хисап аена керем суммасы үсә баручы нәтиҗә белән, мең сум | | | Транспорт оешмаларына хисап аена ташламалы транспорт карталары буенча транспорт хезмәтләре күрсәтүгә бәйле рәвештә түләнә торган компенсация түләүләре күләме, арта барган нәтиҗә белән, мең сум | Транспорт оешмасының чыгымнары арта барган хисап ае өчен ташламалы транспорт карталары буенча транспорт хезмәтләре күрсәтүгә бәйле рәвештә, мең сум | Асылда, хисап аена арта барган (касса чыгымы) белән транспорт оешмаларына күчерелгән, мең сум | Хисап аенда транспорт оешмалары тарафыннан компенсация түләүләренең көтелмәгән күләме арта барган нәтиҗә белән, мең сум .( 9гр.-11гр.) |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | Хисап ае эчендә арта барган нәтиҗә белән файдаланылган ташламалы транспорт карталары/гамәлгә ашырылган ЕМСПБ н, данә | Хисап аена үсә барган нәтиҗә белән ЕМДСПБ тарафыннан тулыландырылган балалар ташламалы транспорт карталары саны, данә | Барлыгы, данә (3гр. + 4гр.) | Ташламалы транспорт карталарыннан алынган/гамәлгә ашырылган ЕМСПБ табыш суммасы, мең сум | Тулыландырылган балалар өчен ташламалы транспорт карталарыннан алынган / гамәлгә ашырылган ЕМСПБ керем суммасы, мең сум | Барлыгы, мең сум.( 6гр. + 7гр.) | | | | |
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 | 9 | 10 | 11 | 12 |
| | | | | | | | | | | | |

Җитәкче _____________________ ____________ _________________________________

*(вәкаләтле зат вазыйфасы, (имза) (имза расшифровка)*

Башкаручы ___________ ___________ ____________________

*(вазифасы) (ФИО) (телефоны)*

«___» ____________ 20__ ел.